**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7629**
**23.11.2021**

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.5.2. пунктның «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«д) инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләү, автомобиль юлларын эксплуатацияләү өчен җаваплы хезмәтләр, эшләр башкару планлаштырыла торган саклык зоналарын балансга тотучылар, җир участокларына хокук ияләре белән килештерү (челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш).».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                        Ф.Ш. Салахов